Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

**2021 елның 23 августы** **№ 33**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32, 23 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кирельский авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельский авыл җирлеге Советының 2013 елның 19 декабрендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кирельский авыл җирлеге»нең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 бүлекнең 35.5 маддәсе Шәһәр төзелеше регламентлары. Инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы зонасы, ИТ-1 территориаль зонасы, күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә:

- су транспорты (эчке су юлларының суднолар йөреше өчен, эчке су юлларын, причалларны, пристаньнарны, гидротехник корылмаларны, навигация җайланмаларын һәм суднолар йөрешен һәм су ташуны тәэмин итү, су транспортын тотыру өчен кирәкле башка объектларны капиталь төзелеш объектларын урнаштыру) сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кирельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы ,
Совет рәисе Ф.Я. Зиннәтуллин